ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2024 г.Лениногорск № 564/1

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021елның 6 июлендәге 626 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Лениногорск шәһәр прокурорының 2024 елның 5 мартындагы 02-08-03-2024/прдп142-24-20920049 номерлы протестын карап чыгып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021елның 6 июлендәге 626 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт судьясы квалификация категориясен бирү документлар комплекты белән гариза теркәлгәннән соң ун алты эш көне эчендә башкарыла.»;

3.4.1 п. алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спорт разрядын бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разрядын бирү өчен документларны карау тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителергә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү һәм хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе, Россия Спорт министрлыгының 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы (24.01.2024 ред) «Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында Нигезләмәне раслау турында» боерыгы белән расланган бердәм Бөтенроссия

спорт классификациясе турындагы Нигезләмәнең 57 пунктында билгеләнгән».».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор – «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар өчен ачык булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Хайбрахманов И.Р.
5-44-72